ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЗЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Советская, д.22,

с. Азеево,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА
ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ АКЪЯР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Совет урамы, 22,

Акъяр авылы,423190

тел.: (8- 84348) 3-71-31, факс: (8-84348) 3-71-61 Azeev.Nsm@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

2024 нче елның 15 феврале

КАРАР

№ 3

Хуҗалык китапларын салу турында

«Җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы, «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Хуҗалык китапларын алып бару формасын һәм тәртибен раслау турында» 2022 елның 27 сентябрендәге 629 номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Акъяр авыл җирлеге Уставына таянып, авыл җирлегендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алу максатларында, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Акъяр авыл җирлеге башкарма комитеты

карар бирә:

1. 2024 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Акъяр авыл җирлеге буенча шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алуның хуҗалык кенәгәләрен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең бухгалтерлык һәм махсуслаштырылган хисапларын җыю һәм эшкәртү комплексы мәгълүмат системасыннан файдаланып, агросәнәгать комплексына ярдәм итү өчен субсидияләрне мониторинглау, исәпкә алу, тикшереп тору һәм анализлау җыелма хисаплар формалаштыру (алга таба - мәгълүмат системасы) электрон рәвештә алып барырга.

2. «Хуҗалык кенәгәләрен алып бару формасын һәм тәртибен раслау турында» Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2022 елның 27 сентябрендәге 629 номерлы боерыгы белән расланган тәртиптә, 2024 елдан 2028 елга кадәр чорга шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алу кенәгәләрен нигезләүне җирлекнең түбәндәге торак пунктлары буенча оештырырга:

| №п/п | Торак пункты | ОКТМО |
|---|---|---|
| 1. | Акъяр авылы | 92645401101 |

3.Ел саен 10 гыйнвардан 15 февральгә кадәр чорда шәхси ярдәмче хуҗалыкларны тоташ йөреп чыгу һәм шәхси ярдәмче хуҗалыклар әгъзаларын сораштыру юлы белән 1 гыйнварга булган мәгълүматлар җыярга.

4.Хуҗалык кенәгәләрен алып бару өчен җаваплы итеп билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Акъяр авыл җирлеге башкарма комитеты секретарен билгеләргә.

5.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» рәсми сайтында: http://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында: http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районының
Акъяр авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе

Д.С.Гайнуллин